# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**Мамадыш муниципаль районы Көмеш-Күл авыл җирлеге составына керүче Алгай торак пунктында үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

№ 3 25октябрь, 2024 ел

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1,56нче статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ санлы Татарстан Республикасы законының 35 нче статьясы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Көмеш-Күл авыл җирлеге муниципаль берәмлеге» Уставының 23 статьясы, Мамадыш муниципаль районы Көмеш-Күл авыл җирлегенең Алгай торак пунктында 2024елның «25» октябрендә узган үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча түбәндәге сорау буенча гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә:
«Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Көмеш-Күл авыл җирлеге Алгай торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 һәм 2 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы һәм сугыш хәрәкәтләре ветераннарыннан, Бөек Ватан сугышында һәм сугыш хәрәкәтләрендә катнашучыларның тол хатыннарыннан, МХОда катнашучылардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан(хатыннары һәм 18 яшькә кадәрге балалары), күп балалы гаиләләрдән, көндезге формада укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан тыш, 2025 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм ул акчаларны түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотылуына сез ризамы:

-Алгай торак пунктында тышкы яктырту урам челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны , бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җайланмаларны (энергияне саклый торган лампочкалар сатып алу һәм алыштыру) ремонтлау;

-Алгай торак пунктында торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (вак таш сатып алу, салу; юлларны кардан чистарту һәм грейдерлау, эшләр өчен шартнамә буенча түләү).

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:
сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 163 кеше кертелгән;

гражданнар җыенында тавыш бирүдә катнашучылар саны: 98 кеше, 60,1% тәшкил итә:
Гражданнар җыенында катнашучыларның ачык тавыш бирү нәтиҗәләре түбәндәгечә бүленде:
«РИЗА» позициясе өчен 98 граждан тавыш бирде;
«КАРШЫ» позициясе өчен 0 граждан тавыш бирде;

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1.Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча Мамадыш муниципаль районы Көмеш-Күл авыл җирлегенең Алгай торак пунктында узган гражданнар җыенын - уздырылган, нәтиҗәләре - дөрес, дип танырга.

2. Мамадыш муниципаль районы Көмеш-Күл авыл җирлегенең Алгай торак пунктында түбәндәге сорау буенча узган гражданнар җыены карарын кабул ителгән дип танырга: «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Көмеш-Күл авыл җирлеге Алгай торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 һәм 2 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы һәм сугыш хәрәкәтләре ветераннарыннан, Бөек Ватан сугышында һәм сугыш хәрәкәтләрендә катнашучыларның тол хатыннарыннан, МХОда катнашучылардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан(хатыннары һәм 18 яшькә кадәрге балалары), күп балалы гаиләләрдән, көндезге формада укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына хәрби хезмәткә акчаларны түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотылуына сез ризамы:

-Алгай торак пунктында тышкы яктырту урам челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны , бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җайланмаларны (энергияне саклый торган лампочкалар сатып алу һәм алыштыру) ремонтлау;

-Алгай торак пунктында торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (вак таш сатып алу, салу; юлларны кардан чистарту һәм грейдерлау, эшләр өчен шартнамә буенча түләү).

3. Әлеге карарны Көмеш-Күл авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Көмеш-Күл авыл җирлеге башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Мамадыш муниципаль районы
Көмеш-Күл авыл җирлеге Башлыгы,
Совет рәисе И.Н.Сәләхетдинов